**Галәү Мәхмүт**

# Г. ТУКАЙ ТУРЫНДАГЫ ИСТӘЛЕКЛӘРДӘН БЕР КИСӘК

Казанда Харитонов типографиясендә эшләгән чагым. Көндез, эштән туктап, ике сәгать ял итәбез. Аш ашар өчен «Болгар»га йөрим. Аш залы өченче катның почмагында иде. Залдан номерлар ягына – коридорга өске яртысы пыяла бер ишек чыга. Шул ишек белән янәшә үк уң кул якта «40 нчы номер» – Тукай яшәгән бүлмә. Ул җаны тыныч чакта яланбаш, жилеттан килеш, һәр ике кулын чалбар кесәләренә тыгып, озын коридорның бер башыннан икенче башына тик уйланып йөри. Син аш ашап утырган чакта, ишекнең югарыгы пыяла өлеше аркылы кыска чәчле баш түбәсе, җыерчыклы маңгай һәм елтыраган күзләр күреп каласың. Бик яхшы беләсең: бу – Тукай. Димәк, аның бүген җаны тыныч – коридорда йөри... Бирге башка килеп, кире борылган чакта, үрелеп кенә ишектән аш залына күз салып уза. Әгәр ул коридорда күренмәсә, я өйдә юк, яки урында ята, кәефсез.

Тукай гадәттәгечә коридорда күренмәсә, мин анын хәле белән кызыксына идем. Аш тәмам булгач, узышлый номер ишеген ачып карыйм. Әгәр Тукай кроватьта булса, кереп, хәлен белеп чыгам. 40 нчы номерның ишеге һичбер вакытта да бикләнми иде.

Исхак Бикчуринның * асылынып үлү хәбәре таралган чорлар иде. Бер көнне Тукай коридорда күренмәде. Аштан соң бүлмәсенең ишеген ачып карадым. Кровать өстендә тәрәзәгә таба сузылган ботинкалы аяклары күренгәч, акрын гына атлап эчкә кердем.

** Февраль революциясеннән соң бу кешенең провокатор булганлыгы ачылды,*

Бик күптәннән таныш тар гына бүлмә. Ишекнең уң ягындагы элгечтә җимерек фуражкасы, төймә тишегеннән генә асылган пальтосы һәм якасы-нисе белән бергә салып эленгән тышкы күлмәк. Түрдә – тәрәзә янында сул якта ялангач өстәл, бер урындык. Уң якта каты матрацлы тимер кровать. Тукай, аякларын тәрәзәгә, башын ишеккә биреп, сузылып чалкан яткан.

Миңа ул «Мәрҗән» дип эндәшә иде.

– Ә... синме, Мәрҗән?.. Әйдә! – дип каршы ала да, минем «шагыйрь»легемнән иптәшләрчә көлеп, берәр һөҗү әйтмичә калмый иде. Бу юлы башын гына күтәреп карады да, тавышсыз-тынсыз тик ята бирде. Мин караватның янына ук килеп Тукайга төбәлдем. Кечкенә генә ак төшкән бер күзе бөтенләй үлек төсле, теге күзе дә ниндидер әрнү белән нәүмиз генә карый.

– Хәлләр ничек? – дидем.

– Ятам.

– Ни булды?.. Әллә авырыйсыңмы?

– Юк... Кешеләргә бик ачуым килде әле...

Артык төпченеп сораша башласаң, ул бөтенләй телсез кала, әйтәсе сүзен дә әйтми. Бер сүзне башладымы– зур тынлыктан соң булса да, ул аны үзе тәмамлар. Саран кинаяләр белән генә булса да йөрәгендәген барыбер аңлатыр. Көтәргә кирәк. Күземне аннан алмыйча гына «кешеләргә бик ачу» килүнең сәбәбен белергә теләвемне аңлатып урындыкка урнаштым. Берәр минут тик торганнан соң гына, сүзне дәвам иттерде:

– Солтан (Рахманкулов) көзгемне урлап чыккан. Сораса, мин үзем бирмәс идем микәнни?

Ләкин кәефсезлекнең төп сәбәбе бу түгел. «Солтанның көзге урлавы» монда бер сылтау гына. Чөнки миңа бик күп тәҗрибәләр белән анык: Тукай «көзге урлану» өчен генә шулчаклы кәефсезләнә торган кеше түгел. Аның көзгесен генә түгел, бөтен нәрсәсен урлыйлар. Шигырьләрен, гонорарын, авторитетын... Хәтта саф вөҗданына, намусына һөҗүм итәләр. Үз тәгъбире белән әйткәндә, «ак күгәрченне кулыннан кара козгынга алмаштырып алалар». Тукай бу угрылыкларга шигырьләрендәге әрнү-ачыну кыллары яки «һөҗү» җырлары белән җавап бирә, ә болай авыруга сабышмый иде. Тукай үз бүлмәсенә нәрсә генә алып кайтып куймасын, һичберсе яшәми, кемнәрдер шул көндә үк алып чыгып китәләр.

*Һөҗү – сатирик сүз.*

Залда ашап утырган чакта берәрсенә кара-каләм кирәк булса, аны буфеттан алдыру урынына, Тукай бүлмәсеннән генә алып чыга да шунда калдырып чыгып китә. Тукай аны эзләп йөрми. Кыскасы, берәр әйберсе югалу аркасында гына Тукайньщ бу чаклы кәефсезләнү ихтималы юк. Монда ни булса да бүтән бер сәбәп бар иде. Фикеремне Тукайга да аңлаттым.

Ул тагын беравык тын ятты да ияге белән өстәл өстенә ишарәләде:

– Шунда бер нәрсә бар. Укып кара әле!..Таратып ташланган озынча кәгазьләр өстендә яңа гына язган шигыре ята иде. Алып укый башладым:

Котылмакчы булып татсыз хәяттан,

Гомергә җан авырттыргач газаптан,

Гакыл бу, дип, үзеңне үзең үтердең,

Тынычлык эзләдең дә гүргә кердең.

Әгәр син катле нәфес итмичә торсаң,

Җаныңны изгелек берлән тутырсаң,

Ачар ирде ходай бәхетеңне шаять,

Ашыктың, эшләдең бик зур җинаять!

Газап китми кабердә тән черүдән,

Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән.

Бу әлеге «Катиле нәфескә» дигән шигырь иде.

Кәефсезлегенең сәбәбе инде ачык. Исхак Бикчурин «фаҗигасе» аңар шулчаклы нык тәэсир иткән икән.

Шигырьне укып чыккач, Исхак Бикчурин ише бер «нигилист»ка карата «ходай бирәчәк бәхет» белән кызыктыру һәм «гүр газабы» белән куркытуның урынсыз-лыгы хакында сак кына бер фикер әйттем. Тукай сикереп торды. Кровать читеннән аякларын салындырып утырды.

– Син аңламадың алайса, Мәрҗән! – диде, – монда мәсьәлә чатан Исхакта түгел...

Бикчурин аксак иде. Тукай аны «чатан Исхак» дип йөртә иде.

– Нәрсә ул чатан Исхак?.. Тырнак төбенә чыккан«эт тырнагы». Я үзе берәр җирдә өзелеп төшеп кала, яки үзеңне борчый башласа, икенче кулыңның тырнагы белән чеметеп өзәсен, дә урынына йода сөртәсең...

*Катле нәфес итмичә – үзеңне-үзең үтермичә.*

– Алайса... нәрсәдә, кемдә соң мәсьәлә?

– Бөтен яшьләрдә... Синдә, миндә, Мөхәммәт - Әминдә... Сәяси реакциягә ияреп дин реакциясе килә. Әнә Габдрахман (Мостафин) башына бүрек өстенә җөббә киеп җомга намазына йөри башлаган. Кәрәм (Г. Кәрәм) белән Һарун (Апанаев)ны әйткән дә юк. Бераздан Сәгыйть (Рәмиев)нең дә чалма киеп, «биш вакыт»ка йөри башламавына ышанасыңмы?..

Ни әйтергә теләгәнен аңлап бетерә алмавымны белдергәч:

– Чөйне чөй белән бәреп чыгаралар, – дип җавап бирде.

Мин үз юлыма китәргә әзерләндем Тукай күзләрен миңа төбәде.

– Бүген кич нишлисең?

Бу сорауның мәгънәсе миңа бик ачык иде. Үтә кәефсез чагында ул зәп-зәңгәр төтенле, сасы, шахшы сыраханәләрдә утырып төн уздырудан ямь дә, тәм дә таба алмый. Вакыт уздырыр өчен бүтән бер урын кирәк.

– Сәгать җидедә эштән бушыйм, – дидем.

– Алайса киттекме?

– Ярый... киттек.

– Мин «чебенханә»дә булырмын, килерсең? «Чебенханә» дип ул «Болгар» астындагы «Юл» көтепханәсен атый. «Болгар»ның Кабан күле ягына – яңа электростанциягә караган кечкенә генә бер кибет. Бер як күршедә «Постоялый двор» һәм сыраханә. Икенче якта ит кибете. «Көтепханә» эчендә шыр ялангач, буп-буш шүрлекләр. Алучысы да, сатучысы да, сатарлык товары да юк. Нәрсә белән киченүләре тик үзләренә генә билгеле булган хуҗалар – Әхмәт Урманчиев белән Якуп Хәлили кайдадыр бүтән эшләр белән йөриләр. «Көтепханә»дә бер кечкенә малай чебеннәр белән талашып тик утыра. Ә чебеннәр!.. Чебеннәр!.. Керүченең күзләренә, кулларына, авыз-борыннарына тулалар. Шүрлек, прилавка һәм өстәл, урындыкларның элекке буяулары күренми. Читтән кергән кеше анда биш кенә минутка да түзеп тора алмый.

Шулай да Тукай үзенең дус-ише белән очрашуны шунда билгели; көткән кешесе килгәнче әлеге малай белән берәр уен уйнап юана иде. Бервакытны шушы «чебенханә»гә ни өчен шулчаклы зур мәхәббәт куюның сәбәбен сорадым.

– Бүтән урын юк. Кайда барыйм соң – диде Тукай.

– Барсаң, урын җитәрлек. Мәсәлән, «Гасыр», «Сабах», «Мәгариф».

– Аларда кеше күп очрый. Беләсең, хәл-әхвәл сорашкан булалар. Кайбер гакыллы башлар сиңа үгет-нәсихәт бирергә тотыналар. «Нашир»ләре дә берәр«мәҗмуга» сорый башлыйлар. Яратмыйм... Ә «чебенханә»дә без малай белән рәхәтләнеп кузна уйныйбыз, ичмасам.

Кибетләр ябылыр вакыт җиткәндә генә, мин «чебен-ханә»гә килеп кердем. Тукай инде шунда; аның өчен зуррак үлчәүле кара фуражкасын колакларына хәтле басып кигән; керле «ак яка»га иске

галстук та аскан булган; әлеге малай белән чүкердәшеп кузна уйный иде. Бергәләп киттек. Державин бакчасына менеп утырырга булдык.

Балык базарында (хәзерге Куйбышев урамында), ниндидер панорама ачылган. Ишек төбендәге кеше кыңгырау шалтыратып, карлыгып беткән тавышы белән «пожалосто, пожалосто» дип кычкыра-кычкыра тамашачылар җыйный. Тукай кызыксынып та куйды:

– Карап чыкмыйбызмы, Мәрҗән?

Мин каршы килмәдем. Бишәр тиен түләп «панорама» карарга кердек.

Бүлмә эче караңгы. Стена буйлап түгәрәк пыялалы якты тишекләр тезелгән. Тишектән элек биткә эссе бәрелә. Аннан зур керосин лампасы күрәсең. Каршыда – зурайтылган рәсем. Бүгенгедәй хәтеремдә – рәсемнәр «Неаполь» һәм «Венеция» күренешләре иде. Йортлар, күлләр, таулар, көймәдә йөрүче кешеләр панорамада җанлы булып күренәләр. Без бүлмәне әллә ничә тапкыр әйләнеп, панораманы авыл малайларынча кабат-кабат тамаша иттек. Тышка чыккач матур күренешләргә сокланганымны әйттем:

– Нинди бәхетле кешеләр яши икән шундый җирләрдә?

Тукай елмайды да, беравыкка иреннәрен генә кыймылдатып тын барды. Аннан кинәт сорап куйды:

– Печән базары мәчетенең рәсемен күргәнең бармы?

– Бар.

– Әллә шул рәсемне «Неаполь»гә илтеп панорамада күрсәтсәң, синең төсле үк: «Печән базары мәчете тирәсендә нинди бәхетле кешеләр яши икән?» дип сораучылар табылыр иде.

– Әгәр мәчет астында «күкәй салып» утыручы, узган-барганга өреп калучы Мөхәммәтҗан хафизны анда илтсәң, читлеккә ябып «зверинец»та да күрсәтерләр иде бит? – дидем.

– Һәр җирнең үз «Печән базары», һәр Печән базарының үз «Мөхәммәтҗаннары» була...

Танышлар очрап иярмәсеннәр өчен бакчаның иң караңгы почмагына кереп утырдык. Төн уртасы якынлагач, баскыч астындагы «закусочная»га төшеп, бераз тамак ялгап алдык та, извозчиклар торган почмакка килдек:

– «Пески»гә күпме аласың?

Извозчик илле тиен сорады. Мин кыйммәтсенеп сатулаша башладым.

– Сатулашма, Мәрҗән! – диде Тукай, – «өйләнгән»елны егетләр юмарт булалар.